Казан шәһәре Думасының
2024 елның 7 августындагы 5-31 номерлы карары

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге**

**Уставына үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законның 28 статьясындагы 3 өлеше, 44 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы законының 7 статьясы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 82, 83, 84 статьялары нигезендә Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Думасының 2006 елның 8 июнендәге 5-9 номерлы, 2007 елның 16 августындагы 7-19 номерлы, 2008 елның 26 июнендәге 15-31 номерлы, 2009 елның 29 апрелендәге 16-40 номерлы, 2010 елның 10 мартындагы 11-48 номерлы, 2010 елның 8 октябрендәге 2-54 номерлы, 2010 елның 6 декабрендәге 13-2 номерлы, 2011 елның 24 октябрендәге 14-8 номерлы, 2012 елның 19 апрелендәге 9-13 номерлы, 2013 елның 13 февралендәге 15-20 номерлы, 2013 елның 25 декабрендәге 16-28 номерлы, 2014 елның 25 июлендәге 16-34 номерлы, 2015 елның 4 мартындагы 30-41 номерлы, 2015 елның 7 сентябрендәге 13-45 номерлы, 2016 елның 20 апрелендәге 16-6 номерлы, 2017 елның 25 февралендәге 43-13 номерлы, 2017 елның 27 сентябрендәге 7-20 номерлы, 2018 елның 17 апрелендәге 21-25 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге 16-30 номерлы, 2019 елның 18 апрелендәге 14-33 номерлы, 2020 елның 28 февралендәге 14-38 номерлы, 2020 елның 21 октябрендәге 8-2 номерлы, 2021 елның 29 июнендәге 4-7 номерлы, 2022 елның 15 апрелендәге 18-13 номерлы, 2022 елның 22 ноябрендәге 17-18 номерлы, 2023 елның 14 июнендәге 4-23 номерлы, 2024 елның 26 апрелендәге 21-29 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Казан

шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен юлларга.

3. Әлеге карарны, дәүләт тарафыннан теркәгәннән соң, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

4. 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2024 елның 7 августындагы
5-31 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр**

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 32 статьяның 3 өлешендә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 13 пункт белән тулыландырырга:

«13) аңа чит ил агенты статусы бирелгәндә»;

1.2. 13 пунктны 14 пункт дип санарга.

**Башлыкның**
**беренче урынбасары** **Д.Г.Калинкин**